

Раф Гази

# Җәмиләнең яшел күзләре

Наргис Харасова

# Мәхәббәттә абыну

18+

**Раф Гази**
**Наргис Харасова**

# Җәмиләнең яшел күзләре. Мәхәббәтә абыну

*http://www.litres.ru/pages/biblio_book/?art=57128603*
*SelfPub; 2024*
*ISBN 978-5-532-04727-3*

## Аннотация

Һәр хатын-кыз зур һәм чиста мәхәббәт турында хыяллана. Әмма мәхәббәткә төрле юллар бар. Кайчагында алар бик авыр була. Бу хикәяләр җыентыгында үз мәхәббәтләрен, бәхетләрен эзләүче ике хатын-кызның язмышы тәкъдим ителә.

# Содержание

Җәмиләнең яшел күзләре 4
Мәхәббәтә абыну 20

# Наргис Харасова, Раф Гази Җәмиләнең яшел күзләре. Мәхәббәтә абыну

## Җәмиләнең яшел күзләре

### 1

Ватсаптан бер хәбәр килгән иде. Ачып карасам, Җәмиләдан икән. Менә көтмәгәндә, уйламаганда.

"Сәлам! Мин хәзер Казанда. Синең белән очрашып, сөйләшмәкче идем. Бик җитди бер мәсьәлә бар", – дип язылган иде анда.

"Нәрсә турында?" – дип сорадым.

"Синең белән минем хакта", – дигән җавап килде.

Чынлап әйткәндә, бераз аптырап калдым. Бу мизгелдә башыма нинди генә уйлар килеп китмәгәндер. Бәлки, Җәмилә йөккә узгандыр? Алла сакласын! Юк ла! Бер генә мәртәбә булды бит. Мин барысын да контрольдә тоттым. И-и, нәрсә баш ватам соң? Хәзер шалтыратам да үзеннән сорыйм.

– Әлү, Җәмилә, сәлам! Син үзең генәме? Сөйләшә алasыңмы?

– Әйе, әйе, тыңлыйм!

Тавышы тыныч тоела. Хәерлегә булсын!

– Нинди житди эш килеп чыкты анда? Син сау-сәламәттер дип өметләнәм.

– Әлбәттә, сәламәт! Нигә болай каушап калдың әле? Нәрсәдән куркасың?

Җәмилә бераз торгач көлеп тә җибәрде.

– Нигә мин куркырга тиеш, – дидем. – Бер нәрсәдән дә курыкмыйм.

Минем хафалануымны сизде бугай. Менә нинди сизгер ул хатын-кыз.

Гүя мин аның серле, сихерле яшел күзләрен күргәндәй булдым.

– Мин Ходай Тәгаләдән генә куркам, – дип өстәп куйдым да, Казанда кайда урнашканын сорадым.

– Яңа фатир алдым ич. Сиңа сөйләгән идем. Киләсеңме? Адресымны язып ал…

Ә-ә, менә кайда икән ул йорт. Кварталда гына.

Ярты сәгать тә үтмәде: мин ул фатирның зур, якты аш бүлмәсендә, матур агач өстәл янында, Җәмиләнең моңлы яшел күзләренә карап, утыра идем.

Ә Җәмилә бит чыннан да сихирче булып чыкты. Ничек аны белдем? Хәзер барысы турында да тәртип буенча сөйләячәкмен.

## 2

И-иһ, Җәмиләнең яшел күзләре! Ничектер мин бу карашта тәмам эредем, югалдым…

Күрешү башында ул нишләптер үз яшен яшерә иде. Әүвәл "миңа 32 тулды" дип әйтте. Аннары – 35. Ахырыда – 38.

– Бу синең төгәл яшеңме? – дип сорадым Җәмиләдан елмаеп. – Курыкма, тагын өстәп куя аласың, барыбер мине куып җитә алмыйсың.

– Миңа – 38 яшь! – җавабы бик кырыс ишетелде.

… Ничек кочаклашып, түшәккә ауганыбызны һич тә искә төшерә алмыйм. Шуны гына хәтерлим: аның кечкенә, матур гәүдәсе нәкъ мин яраткан төсле ап-ак һәм йомшак иде; әйтерсең мамыктан, якты болытлардан ясалган. Тудыра да инде Раббыбыз могҗизаларны!

Яңа хатын-кызга күнегү өчен байтак вакыт кирәк. Миңа калса, гәдәттә 2–3 очрашу. Җәмиләга исә бик тиз ияләштем.

Ул шундый кайнар, оста һәм миңа бик якын зат булып күренде – гүя мин аны туганнан бирле белә идем. "Күптән секс белән шөгыльләнгәнем булмады", – дип дулкынланып пышылдады колагыма Җәмилә.

Ир-ат мактанычы дерелдәп торган әләттәнәселгә кергәч, мин моны шунда ук сиздем. Күпләр мондый чакта күзләрен йомып ята. Җәмиләнең серле күзләре ап-ачык иде. Мин

аларның яшел, төпсез чоңгылына баттым. Әкиятме бу, чынбарлыкмы? Без икәү, хисләр дәрьясына чумып, мәхәббәт томанында югалдык… Күпме вакыт үткәндер – Алла белә…

Нинди ләзәт! Нинди рәхәт! Кыямәт сәгатенә кадәр шушы җәннәт диңгезендә йөзәр идем.

Әмма тәкъдир каләме минем кулда түгел шул.

# 3

Икенче көнне Җәмилә миңа тагын шалтыратты. Телефонда аның үзенчәлекле тавышы ишетелде. Болай Себер татарлары гына сөйләшә. Себердән Казан җиренә күчүенә карамастан, аларда ничектер шундый йомшак шивә сакланып кала.

– Менә синең китабыңны укыйм, – дип җиткерә миңа Җәмилә. – Бер сүзне аңлам бөтермим. Ереглар – кемнәр алар?

Кемнәр булсын, рухи затлар – мин шундый әкияти персонажларны сурәтләдем ич.

Кичә Җәмиләгә фэнтези жанрында язылган бер китабымны бүләк иткән идем. Ул бик сөенде, шатланды.

– Мин синең бөтен китапларыңны укып чыгармын, – дип тә әйтеп куйды әле.

Бирсен Ходай! Тик ниндидер бер шомлы сиземләвем борынлады. Ереглар – шалтырату өчен бер сәбәп кенә, төп маскаты башка иде аның.

Дөрес сизенгәнмен икән.

– Бик борчылам – якын дустым югалды ич, – дип сөйли башлады Җәмилә. – Өченче тәүлек мобиласы дәшми. Рәмилә миннән биш яшькә яшьрәк, инде күптән Казанда яши. Мине дә монда чакырды.

– Бәлки, Казан егетләре белән күңел ачып йөри, – дип шаяртып карадым мин.

– Мөмкин, элек тә шулай юкка чыгып торганы бар иде. Тик мин барыбер никтер борчылам. Шактый сәер төш димме, күзаллау димме күрдем.

– Нинди төш ул?

Телефон бераз дәшми торгач, моңсу тавыш ишетелде:

– Рамилә тиздән үләчәк.

– Әллә ниләр гөманлама! Юк-бар сөйләмә әле.

– Ул юк-бар нәрсә түгел. Мин төгәл беләм.

– Кайдан беләсең аны?

– Минем шундый сәләтем бар. Кемнең кайчан үләчәген беләм.

– Нәрсә!!!

– Әйе, бик күп кешенең зиратта ятканын күрәм мин.

– Ул төш-күзаллаулар дөрес булып чыгамы?

– Чынга туры килә. Берничә ел элек беренче ирем белән әтием мәрхүм булды. Рухларын Ходаем үз хозурына алсын иде.

– Әмин! Шулай булсын!

– Мин бу хәлнең килеп чыгасын алдан ук белеп-сизеп тордым. Аларны үтерделәр. Бизнес…

Мин шаккаттым! Ышаныргамы, ышанамаскамы бу башка сыймый торган күрәзәчелеккә? Кеше ышанмаслыкны дөрес булса да сөйләмә, диләр ич. Һич тә ышана торган нәрсә түгел бу. Мәзәккә дә охшамаган.

Җәмилә дәшмәде. Нәрсә дип әйтергә белмичә, мин да дәшми тордым. Ниһаять, ушымны җыеп:

– Син теге, ни… сихерче, шаман буласаңмы инде, – дип пышылдадым.

– Шулайрак. Мин бит яшь чакта Себерда, кара урман эчендә үскән, гомер иткән кыз.

– Ярар, алай булса, менә мин кайчан бу дөньядан ахирәткә күчәчәкмен? Әйтәләсеңме?

– Әйтәләм.

– Йә, кайчан? – маңгаема тир бәреп чыкты.

– Кайгырма, – дип юатырга ашыкты Җәмилә. – Син озак яшәячәксең.

– Йөзгә хәтле?

– Анысын белмим. Мин сине ап-ак сакаллы бик карт кеше итеп күрәм.

– Моны мин үзем дә беләм.

– Әйе, син озак яшәрсең һәм барысы да яхшы булачак… Тик менә Рамилә үләчәк.

Янә тынлык урнашты. Аның борчылуы миңа да күчте:

– Җәмилә, син кайда? Кайда син?!

## 4

Менә мин Җәмиләнең яшел күзләренә багып, аның якты фатирында утырам. Чәй эчәм. Соңгы сөйләшүдән бер атна чамасы вакыт узган иде.

– Дөньяның иң гүзәл кызы табылдымы?

Әй мактаган иде Җамилә үзенең теге ахирәткәен. Топ-модель, имеш.

– Кем, Рәмиләме? Шөкер, исән.

– Мин бик шатмын.

– Ярар, әйдә үзебезнең хакта сөйләшик әле.

Мин шөбһәгә төштем. Кайнар чәйне зур зәңгәр кәсәдан яңа ыштаныма түгүемне сизми дә калдым. Җәмилә каушап калуыма игътибар да итмичә дәвам итте.

– Сиңа бер тәкъдимем бар. Сәер тоелса да, тыңлап бетер әле: безгә никах укытырга кирәк.

– Кемгә ул безгә?

– Кемгә?! Кемгә?! Синең белән миңа.

Инде мин чынлап куркып калдым. Көчем китте. Кәсәне төртеп куйдым – нинди чәй инде, элеке шәкертләр әйтмешли, халәте икраһ – ирексез хәлдә булганда. Йә, Ходаем, мәдәт! Нәрсә уйлый бу урман кызы?

– Йә, шуннан!

Җәмилә авыр сулап куйды да, сөйләргә тотынды.

Аның буталчык, каршылыклы сүз сөрешеннән мин менә

нәрсә аңладым.

Теге вакытта телефоннан сөйләшкәннән соң Җәмилә бер ерак авылда кунакта булып кайткан икән. Авылда ул мәрхүм иренең ниндидер бер ерак туганы, бер карчык белән очрашкан. Казандагы бу фатир аныкы икән. Җәмилә, банктан кредит алып, аны сатып алырга теләгән. Тик карчык көтелмәгән кунакны бик нык куркыткан.

– Абыстай, мине рентген кебек үтәли күрде, – Җәмилә куркуларын яңадан кичергәндәй булды. – Ул бөтен тормышымны кинода күргәндәй тасвирлый башлады.

"Әгәр тәүбәгә килмәсәң, языкларың җәзасы балаларыңның башында да төшәчәк", – дип нык кисәткән Җәмиләне теге абыстай. Әмма фатир ачкычларын кире алмаган. Киресенчә, фатирны бүләк итәргә вәгъдә иткән. Әгәр никахлы иреңне авылга алып кайтып күрсәтсәң, дигән.

"Ә-ә, менә ни өчен Җәмиләгә никах кирәк булган икән" дигән нәтиҗәгә килдем мин. Тик нинди гөнаһлары өчен орышкан соң аны күрәзәче әби.

– Нигә миңа шулай сынап карыйсың! – дип кызып китте Җәмилә. – Әйе, мин фахишә! Ләкин мин урам себеркесе түгел, мин «индивидуалка» буларак эшләдем. Ике ай чамасы гына эшләдем. Аннары ташладым. Син – соңгы клиентым булдың.

Алай икән… Нинди саер сүз – "индивидуалка"…

– Тукта әле, мин сиңа акчаңны бирмәдем ич.

– Ничек бирмәдең? Ә 5 000-лекне кем бирде соң? Оны-

тыңмыни?

– Син бит үзең, ипотекага түләргә җитми, дип әйттең.

– Әй, тиле! Син Хуҗа Насретдин кебек ишеткән барча әкияткә ышанасыңмы? Мә, акчаңны, миңа кирәкми ул, – Җәмилә биш меңлекне өстәлгә ташлап, үкси башлады.

…Бу әшәкелеккә аны Рамилә тарткан икән. Ул инде ун ел буе профессионал рәвештә «эшли». Рәмиләнең "ментовская крышасы" да бар. «Крыша» табышның яртысын үзенә ала.

– Әгәр мөшкел хәлдә калмасам, мин бу юлга басмый идем, дип шыңшыды Җәмилә.

Беренче ире белән бергә әтисен үтергәннәр…

Йортларын басканнар…

Бизнесларын тартып алганнар. Шуннан бурычка баткан…

Унике яшьлек кызы бар. Аны ничек тәрбияләргә?..

Ярый әле хәзер баласын әнкәсе карый. Тик ул әтисе бакыйлыкка күчкәч, еш авырый башлаган.

Нинди хисләр кичердем мин, шуны тыңлап? Җәмиләне гәипләдемме? Аны гөнаһлы дип санадыммы? Уйларым буталды. Искә Галимҗан Ибраһимов төште, анын "Татар хатыны нилəр күрми" повесте. Бөтен бәлә татарнын ялгыш кыйбласыннан.

## 5

Җәмилә минем күңелсез уйларымны бүлде:

– Син шундый әшәке кеше белән никахлашырга телә-

мисең инде. Миңа күп кирәкми бит. Мин икенче хатының булырга да риза.

– Хатыным юк! Китте ул, чит илләргә, мин ялгыз калдым.

Бу сүзләрне ишеткәч, ул җанланып китте:

– Алай булгач, нинди каршылык бар.

– Тукта әле, Җәмилә, сиңа бит никах формал рәвештә, теге абыстайның күзен буу, фатир өчен генә кирәк.

– Алай димә! Әйдә, ачыктан-ачык сөйләшик. Менә кара, син – ялгыз, мин дә ялгыз…

– Тукта, ә икенче ирен?

– Нинди икенче ирем?

– Соң син бит гел: беренче ирем, беренче ирем, дип сөйлисең. Димәк, икенчесе дә булган.

– Ә-ә, ул гражданский брак кына иде. Бер яшьтәшем, Дениз исемле төрек егете иде ул. Мин аны куып чыгардым.

– Нигә?

– Ялкау. Мин – ир кеше, диеп, һаман күкрәк сугып утыра, тик кулыннан бер эш тә килми. Бер көн гардинны беркетеп куюын сораган идем. Менә шуны, – Җәмилә ап-ак, матур кулларын югары күтәреп, тәрәзә өстенә ишарәләде. – Ярар, беркетте. Урындыкка утырган идем. Шалт итеп башыма төште ул. Чыдамадым: "Кулсыз тәре! Нарсәгә кирәк син миңа шуны да эшли алмагач. Гардин нык торырга тиеш. Асылынырга да телесәм дә, урыныннан кымшанмаса тиеш", – дип кычкырдым. Кудым! Барыбер бөтен эшне үземә эшләргә туры килә.

Ерак Төркия якларына кайнар сәламемне юлладым – мин дә гардин беркетә алмыйм. Әмма бу хакта сүз кузгатмадым, бары тик үкенечемне генә белдердем:

– Кызганыч. Аның яхшы сыйфатлары бөтенләй юк иде мени?!

– Яхшы сыйфатларымы? Юмарт. Бергә яши башлагач, шунда ук миңа 200 мең сум акча чыгарып бирде. Ләкин алар бик тиз бетте – бурычларыбыз күп иде. Ә ул эшләми, зур акчалы эшне көтә, мин генә чабам.

Җәмилә уйга батты. Тынлык урнашты. Мин салкын чәйны кабып куйдым. Хатын сүзен дәвам итте:

– Денизның тагын бер сыйфаты бар. Белмим яхшымы ул, яманмы? «Секс» дигәнне бик ярата. Чын, гайрәтле төрек егете! Әлбәттә, мин да ул нәрсәдән баш тартмыйм. Ләкин миңа шул хәтле кирәкми. Көнме-төнме, аның эше юк – әйдә алга! Мине өчәр сәгать җәфалый иде.

"Әй, нәсел үгезе, ник изден безнең кызларны?! Безгә нәрсә кала?" – дигән уйлар баш күтәрде бу минутта күңелемдә.

Ә үзем:

– Мин да алай ук булдыра алам, – дип шаярткан булдым, көнләшеп.

– Беләм, күрдем инде, – көлеп куйды Җәмилә. – Сүземне бүлдең. Нәрсә әйтә идем әле… Әйе, син дә ялгыз, мин дә. Сиңа да секс кирәк, миңа да. Нигә безгә никахлашмаска?

– Бәгырем, мин синең өчен бик карт түгелме соң?

– Нинди карт, нинди карт! Син моны кемгә әйтәсең? Бел-

мәсәм, күрмәсәм иде. Беренче ирем дә, мәрхүм, миннән 12 яшькә өлкәнрәк булды.

– 12 яшкә… А монда 12 яшь генә түгел, шактый күбрәк.

– Күбрәк булса ни! Мине бу курткытмый. Никахтан соң без "воскресный брак" төзи алабыз.

– Ничек була инде ул?

– Син үзенең фатирыңда яшисең, мин үземнекендә. Атнага бер-ике мәртәбә синдә яки миндә сагынышып очрашабыз. Миңа шул җитә.

– Шулай дисеңме?

– Шулай дим.

Мин тагын уйга чумдым…

– Юк, җан кисәгем, алай булмас.

– Нигә? – Җәмилә миңа аптырап карап куйды.

– Син әле яшь, чибәр хатын. Тәүбә итсәң, Ходай гөнаһларыңны да кичерер дип уйлыйм. Иһ, кемдә юк ул гөнаһлар.

– Бәлки миңа да намазга басаргадыр?

– Ниятең булса.

– Кызым өчен бик куркам.

– Курыкма! Иманым камил, Аллаһы Тәгалә рәхимле, шафкатьле, ихлас күңелдән тәүбә итсән, кичерер. Тик туры юлыңнан читкә чыкма.

– Мин ант иттем.

– Рамиләдән читтәрәк торырга тырыш.

– Нишләп? Фахишә булгагамы? Ул бит минем ахирәткәем. Мин аны барыбер яратам. Җитмәсә, ул тиздән үләчәк.

– Син аны ничек сизәсең?

– Сизәм инде, – аның күзләрендә кабат яшел сихер уты балкыды.

– Ярый, үзең беләсең. Әйдә, без болай итик. Син теге төрек малае белән никахлаш. Аны начар кешедер дип уйламым. Сез әле яшьләр, сезнең әле уртак балаларыгыз булырга мөмкин. Ә теге гардинны мин да җүнләп беркетә алмыйм.

– Әй, гардинда мыни хикмәт… Мин аны ярсып, каударланып кына орышкан идем. Бәлки син хаклыдыр да. Дениз да еш шалтыратып тора, – Җәмиләнең яшел, сихери күзләре тагын ялтырап китте.

– Ярар, инде мин китим. Тик бер шартым бар.

– Нинди?

– Никахка мине дә чакырырсыз.

– Әлбәттә, рәхмәт сиңа, – дип елмайды Җәмилә, маңгаемнан үбеп.

Әй, ятсыз хатын…

## Эпилог

Яшәгән, ди, борын-борын заманда бер суфи-остаз. Аның бик күп шәкертләре булган. Аның даны, шөһрәте бөтен дөньяга таралган, ди. Солтаннар да, падишаһлар да моның янына сөхбәтләшергә, киңәшергә килгән.

Бер төнне бу суфи төш күргән. Төшенә хур кызыдай бер матур, гүзәлләрнең гүзәле – Алтын Баш падишаһның төп-

чеге кергән. Шунда ук суфи аңа гашыйк булган, күзләренә багып мәхәббәтен аңлатасы килгән.

Шәкертләре, бара күрмә, хур булырсың, бик куркыныч, хәтәр эш, дип үгетләгән. Ләкин ул беркемнең сүзенә дә колак салмаган. Көнбатыш тарафларына сәфәр чыккан.

Күпме баргандыр – бер Алла белә. Ниһаять, Рум иленең башкаласына килеп җиткән. Менә теләгенә ирешергә дә берничә адым калган. Бик зур, бик матур, өч катлы сарайның балконында теге асылъяр басып тора икән. Сары чәчле, зәңгәр күзле сылу шул биеклегеннән барча җиһанга нур сирпеп, елмаеп карап тора. Тик суфины гына күрми чибәркәй.

Бер көн көтә суфи, ике, өч… көн.

Ниһаять, бервакыт моңа да елмаеп куя. Янына чакырып ала. Көлемсерәп тыңлый да, аңа шәригатькә сыймый торган эш куша. Шушы эшне башкарып чыксаң, мәхәббәтеңә ышанырмын, ди шаян кыз. Ул аңа дунгыз абзарын чистартырга боерган икән. Тик суфи озак та уйлап тормый: патша кызның бу шартын кабул итә. Көннәр буе дуңгыз абзарында мәш килә. Шулай итеп байтак вакыт үтә.

Көннәрдән бер көнне суфиның шәкертләре остазын эзләп таба. аңа сәлам бирәләр. Тик алар дунгызларны күргәч, "әстәгыфирулла! тәүбә! тәүбә" дип, остазларын ташлап, үкчәләрен ялтырата. Тик бер ышанычлы шәкерте генә остазы янында кала, абзар чистартырга булыша.

Көннәр үтә, патша кызына кияүгә чыгар вакыт җитә. Бик көяз, елгыр шахзадә дә табыла. Күрәсең, Чибәркәй бу яшь,

кара мыеклы егеткә үзе дә гашыйк була. Түй көне билгеләнә.

Моны ишеткәч, суфи патша кызы катына хушлашырга килә. "Әйткәннәрең үтәлде, бәхил бул", – дип туган иленә кайтып китәчәген җиткерә.

Иртә Чибәркәй икенче көнне иртән торып караса, чынлап та, суфи урынында юк икән. Шул минутта күңелен сәер сагыш биләп ала, күзләреннән яшь ага башлый. Элек картрак күренгән суфи хәзер инде аңа бер тирә яшьтәге, матур гына егет кебек тоела башлый. Тик артыннан чыгып йөгерсә дә аны куып җитә алмый. Кайсы гына шәһәр базарына кереп, мосафирны күрмәдегезме, дип сорашса да, һаман бер җавапны ишетә. "Әй, Чибәркәй, ул суфи кичә генә монда иде, бүген иртүк юлга чыгып китте", – дигән җавап ишетә. Шул рәвешле бер кайда да очрата алмый ул эзләгәнен.

Бичара кыз әй кайгыра, кайгыра. Шулай кайгыга төшеп, көннәрдән бер көнне ахирәткә күчә.

Суфи исә яшәгән шәһәренә кайтып җитә. Шәкертләрен җыеп, бәйрәм ашы үткәрә. Моңланып сазында уйный. Тегеинң ышанычлы шәкертен үз янына чакырып васыятьләрен җиткерә. "Мин бу дөньядан арыдым, ял итәсем килә. Урыныма менә шушы иң сабыр, иң тырыш ярдәмчемне калдырам. Аны мине яраткан кебек яратыгыз. Ул хәзер сезнең Остазыгыз", – дип шәкертләре белән хушлаша. Юк, суфи үлми.

Сазын чиртеп, әле озак еллар яши.

Патша кызы да үлмәгән икән. Аның эчке дөньясы үзгәр-

гән. Ул тәүбә итеп, кыйблага юнәлеп, ислам динен кабул иткән. Теге шахзадәгә кияүгә чыккан. Бер-бер артлы балалары туган. Шулай бергә гөрләшеп гомер иткәннәр.

*Раф Гази*

# Мәхәббәтә абыну

## Пролог

Минем китабым – сихри, күп сораулар, татлы мизгелләр һәм авыр газаплар китергән мәхәббәтем турында.

Күңелемә сыймаслык хәлләр булды. Озак язмый тордым, язмамдыр, сөйләмәмдер, үземнең генә дә көчем җитәр кебек тоелды. Әммә көчем җитмәде шул: кешеләргә ишеттерәсем килә, җәмгыятькә җиткерәсем килә гайбәт өчен түгел, бер гыйбрәт өчен. Менә күңел авырым шул мәхәббәтәндер.

Аерылышканнан бирле көн дә яшь кипмәде күзләремдә. Көчем җитсә үләр идем, ходайга тапшырып. Беләсезме ни өчен, нәрсәдер мине тота яшәүдә, әллә бу көчсезлектән; әллә инде бер яхшы әхлак, әллә бер сәбәп, кешеләр өчен яшәү, – әни өчен яшәү!

Бу чынлап та язмыш булды. Минем сул кулда акыл сызыгы йолдыз шикелле 5 сызыкка бүленә. Ә ул, акылдан язу билгесе, дип әйтәләр. Тик менә уң кулда акыл сызыгы икегә бүленә. Ә андый сызык урысча әйткәндә “гибкость ума” – сыгылмалылык һәм хәйләкәрлекне аңлата диләр. Бәлки, ул мине коткарыр да.

Әйе, сиңа коткарыр? Психушкага әниең белән абыем са-

лып куймасыннармы?

* * *

Бу мәхәббәтнең башлануы да көз көне иде. Бу очрашу 1 октябрь көнне булды. Гадәттә, язгы мәхәббәт бәхетле була диләр, ә көзге мәхәббәтне өзелеп төшкән саргайган яфрак белән чагыштыручылар да бар. Минем мәхәббәтем дә күктәге янып торган йолдызларны каплап, күкне урап алган бүген – иртәгә явам дип торган карлы болытлар чоры иде. Әммә каплый аламы соң бу көзге җил, көзге карлы яңгыр Казан шәһәренең мәдәният сарайларында залларны шыгрым тутырып татар җырын карарга килгән тамашачы күңелен! Соңгы 5 елда татар эстрадасы концертларының кызганнан – кызган чагы. Монда инде Салават та, Хәния Фәрхи, Айдар Галимов, Зәйнәп Фәрхетдинова концертлары турында сөйләп тә торасы юк. Салават август аеның буеннан буена җырлый. Июнь аенда Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билаловка халык чәчәк китереп бетерә алмый. Менә октябрьдә дә чираттагы Нәфкать Нигъматуллин концерт биргән көне иде.

Шушы көндә сәгать алтынчы яртыда безнең өйдә телефон шылтырый. Әнием телефонны ала, анда таныш булмаган тавыш ишетелә:

– Алло, исәнмесез. Сезнең кызыгыз Нурсиләме?

– Әйе.

– Ә мин Әнвәр. Кызыгыз өйдәме? Чакырыгыз әле аны те-

лефонга.

– Ул өйдә юк бит әле. Ә сезгә минем кызым нәрсәгә кирәк соң?

– Ул кайчан кайта соң?

– Җиделәр тирәсендә кайтырга тиеш.

– Бик кызганыч, мин аны концертка чакырмакчы идем.

– Нинди концертка?

– Н. Нигъматуллинның концертына.

– О-о. Аның концертына бу вакытта билетләр сатылып беткәндер, дип әйтте әни кеше.

– Ә минем чакыру билетым бар. Алай булгач, мин телефон номерын калдырам, ул кайткач миңа шылтыратсын. Шуның белән аларның сөйләшүе тәмамлана.

Мин ул көнне музыка мәктәбеннән укытып кайткач, хорда җырлаган өчен шәһәрнең үзәгендә урнашкан университетка барып акча аласы бар иде. Кайтып керү белән, әни сөйләп бирде телефоннан Әнвәр исемле егет белән сөйләшүен.

Мин университетта укып йөргән гади бер кыз. Ике ай алдан егетләр белән танышырга теләп, интернеттан егетләр исемлеге белән таныша башладым. Һәм бер Әнвәр исемле егетне сайлап алып аның белән хат алыша башладык. Шулай бик озак интернетта танышып, хат аша сөйләшкәннән сон, Әнвәр белән очрашырга сүз куештык та очраштык, сөйләштек. Ул миңа бик үк ошап бетмәде, әллә нинди – селәгәй дә әйтеп булмый, тыныч темпераментлы егет булып чыкты. Аннан очрашырга теләк белгертмәде, мин үзем дә әзер түгел

идем, шуңа күрә алдагы очрашуларга көнен билгеләмәгән идек. Кайчан җай чыга-алдагы көн нәрсә күрсәтер.

Ә бүген әнинең: “Кызым, сиңа бер Әнвәр исемле егет шылтыратты, сине, УНИКС концертлар залына Н. Нигъматуллинның концертына чакырды” сүзе мине бик аптыратты. Чөнки әни аңлавынча ул бик конкрет таләпле кешегә ошаган, ди. Әнинең аның сөйләшү рәвеше турында әйткән фикере мин интернеттан танышкан егетнең сөйләшү рәвешенә бик туры килмәсә дә, мин уйладым, бу Әнвәр, – дип. Ләкин икенче сиземләү тойгысы да бар иде, кире хис. Ул Әнвәр, алдан әйтеүемчә, кыюсызрак егет бит тоелган иде дә миңа. Шулай булса да, без әни белән киңәшләштек тә, әни абыйның телефонын биреп торды да, мин киттем очрашырга. Ә ул ахырда, мин интернеттан танышкан Әнвәр булып чыкмады. Сиземләү дөрес булып чыкты. Ул Син булып чыктың. Тик исемнәрегез бер булды. Син мине чынлыкта таптың һәм без карусельдә әйләнгән кебек тормыш ямендә бергә әйләндек. Үзебез дә тоймадык иң бәхетле чакларыбызны.

Мин соңга калып булса да, мәдәният сараена килеп җиткәндә, тамашачы тәнәфескә чыккан иде. Күтәрмәсеннән үк ул мине каршы алды һәм болай диде:

– Мин Әнвәр!

– Сәрвәр?! – кеше күп булганлыктан аңлашырлык итеп исемен ишетмәенчә калганнан һәм теге егетнең дусты дип уйлаганнан – Ә Әнвәр кайда? дип сорадым.

– Мин – Әнвәр. Әйдә киттек. Бәлки, бу язмыштыр? диде

ул.

Минем күңелемә келт итеп бер вакыйга искә төште. Узган елны "Татар җыры" Пирамида мәдәни үзәктә үткән иде. Мин ул концертта булган идем. Һәм бу кешене мин инде шунда беренче тапкыр күргән кебек булдым.

Ә икенче тапкыр мин аны узган шимбәдә күргән идем. Җырчылар арасында "Барс- рекордс" татар җырына бәйге үткәргәннәр. Мин шунда катнашкан идем. Ә ул жюридә утыра иде. Ә алар катнашучыларга әйтеп җибәргәннәр иде, телефоннан без сезне чакырырбыз, дип. Минем менә шуның нәтиҗәсен көтеп йөргән чак. Җыр белән мавыккан чагым иде бу. Әй, мин җыр белән бөтен гомере буена мавыгучылар санындадыр.

– Ярар, әйдә, дидем мин, карышмыйча гына.

Менә шундый ике төрле уй башымда чуалды.

Ишекләрдән кергәндә, әлегә яшь тә, атаклы да кеше белән бергә хатын очрады юлыбызга, алар чыгарга җыендылар. Әнвәр шул дустына әйтте: "Беренче партиясе китә, икенчесе хәзер керә". Мин инде уйладым, болар безне – кызларны тормышта сынап карыйлардыр диеп. Ләкин сынап карау дигән төшенчәне әле аңлап бетермәгән идем.

– Ә син ничек шулай курыкмыйча килдең? – дип сорады ул миннән.

– Минем Әнвәр исемле бер егет – танышым бар. Без аның белән интернеттан таныштык, әле бер очрашып, башка очрашмаган идек. Мин уйладым ул Әнвәр дип, шуңа килдем

аның белән очрашам, дип.

– Ә-һа, димәк, кыюлык. Син бер нәрсәне дә югалтмадың, рисковать итсәң дә, минем күңелемне юатып җибәрде.

– Ә миңа синең әниең әйтте сине телефонсыз дип.

– Миңа аны кайчакларда абый бирә.

Икенче күренеш башлануга без аның белән залга кереп утырдык. Җырчының җырлары берсе дә истә калмады.

– Сиңа ничек бу Н. Нигъмәтуллин җырчы? – дип сорады ул, беләсе килеп минем фикеремне.

– Ә… болай… ярыйсы ла, дидем мин, артык игьтибар итмичә. Чөнки мине инде андый концертлар белән генә шаккатырып булмый. Нинди генә булсам да, мин әле музыкант.

– Синең фамилияң Абдуловмы? дип сорадым мин аннан. Чөнки жюри әгъзасы нәкъ Абдулов исемле кеше булган һәм мин аны аңа охшаттым.

– Юк, Хабибуллин, – диде ул.

Бер сүз дәшми югалып калдым һәм концертны тыныч кына карап утырдым. Чөнки мин уйладым – ул жюриның сүзе үтүле әгъзасы дип. Концерт ахырында ул әйтте: Әйе, мин шул Абдулов булам. Ярый, димәк мин ялгышмадым.

Концерттан бергә чыгып киттек. Ул мине озата китте. Барабыз шулай, бер ресторанга керергә тәкъдим итте. Кердек. Ул сыра алды, ә мин бер стакан сок алдым. Акчаны ул түләде. Әзрәк утырдык та, чыктык. Ул мине озатып куярга булды.

– Беләм инде, кешеләрне сыныйсыз, дидем мин.

– Әйе, дөрес. Һәм ул миңа интернеттагы шәхси һәм эш

адресын да бирде.

Безнең күңелләр очрашкан кебек булды. Бер- беребезне аңлаган кебек тоелды миңа. Без иртәгә сәгать кичке 5 тә очрашырга сөйләштек. – Әйдә, чәй эчеп чыгасыңмы соң? дип тәкъдим ясадым аңа. Аның шатланудан күзләре йөгерә башлады. Ул риза булды. Без мендек, ишекне әни ачты. Мин әйттем, без чәй эчергә килдек, дип. Ә әни: “Бүген соң инде, башка вакыт булыр әле”,– диде. Бу егетнең дә өенә кайтасы бар бит әле, транспорт туктар бит, диде. Чынлап та сәгать төнге 12 нче ярты иде. Әнвәр ничектер үзенең эченә йомылган кебек булды да, – ярый, мин киттем, – дип, чыгып та китте. Шул вакыт әниемнең шулай коры гына әйткән сүзеннән, мин коелып төштем. Гадәттә, ул һәрвакыт кунакчыл була торган иде. Мин сиздем Әнвәрнең үпкәләп чыгып киткәнен. Ә әнием ничектер аңлаган аның интернеттагы мин танышырга сүз куешкан егет түгел икәнен. Әнвәр турында әнинең беренче калган тәэсире: кепкасын күзләренә төшереп кигән бандит бит бу, яшь егет түгел, ул. Буе бәләкәй генә.

– Нишләп шундый егетләргә күзең төшә синең. Үзең менә дигәнсең шикелле. Киеме дә шалапайныкы кебек. Кем белән таныштың син, кызым, диде.

Ә мин әйттем: “Әни, беләсеңме бу кем? Бу бит мин җыр бәйгесендә,кастингта баш булган жюри рәисе”. “И, ния чыгарып җибәрдең син аны. Алай булгач, кыстарга кирәк иде. Нәрсә соң җебеп торасың?!” диде ул.

* * *

Икенче көн.

Бу көнне мин эштән сорап киттем аның белән очрашырга. Аның белән күрешер өчен алданырак кайтып бизәнергә ашыктым.

Матур кара итәгемне һәм ак модный блузкамны кидем. Итәк тезләрдән югарырак иде.

– Сәлам!

– Сәлам!

– О-о, синең нинди матур итәгең, – мин елмаеп күземне төшердем. Без урам буйлап киттек.

– Әйдә, сөйләп җибәр. Син кайдан, сиңа ничә яшь?

– Бер үзең торасыңмы? Кем белән торасың?

– Әйдә, син үзең турында сөйләп җибәр башта, – бүлдердем мин аны.

– Мин… Алдауны ул тезеп китте. Аңа үзенең информациясен мин белеүе бер дә кирәкми иде. Чөнки холкы да, эше дә шул: кешедән соратырга, үзеннән чыгартмаска. Бу кешенең намусы юк икәнлеген шунда ук игътибарлы укучы аңлап алыр.

Минем холкым бигерәк бер катлы булганнан, самими булганнан:

– Минем әти әни белән аерылганнар, абый, апа бар. Кастингга бер дус кыз белән килгән идек, Ләйсән исемле. Ул

үттеме? сорап алдым.

– Белмим, аны карарга кирәк видеодан, юк бугай.

Шул вакыт ул мине кулдан алды. Куллар очрашса, күңелләр канатлана. Бер тукталыш алга атлап куллар тотышып барырга булдык. Яратам бит мин аны, берничектә оныталмам, чөнки миемнең иң нечкә җепләренә ябешкән аның белән булган хәтирәләр, хисләр. Аннан миңа көзге җилләрдән салкын булганын сизеп, ул ресторанга керергә тәкъдим итте. Мин ризалаштым.

Аннан китте кияүгә чыгасың киләме дип сүзләре, үз профессиональ җырчы юлың нәрсәдән торырга тиеш дип сораулары, нәрсә ул миңа булыша алуын дигән сүзләре.

Күп сүзләр сөйләнелде. Шушы көн мәңгегә истә калыр сыман. Кайтыр юлында ул минем кулларымнан алды. Шул чак минем бөтен тәнемнән әллә нинди ток узган кебек булды. Әйтерсең лә, ул мине үзенә магнит белән тарта. Миңа бик кадерле булган бу мизгелдәге хис – тойгылар, мәңгелек исемдә калды. Үбештек!!!!!!!

Ләкин мондый мизгел кызганычка каршы бер дә кабатланмады. Төш кенә минем коткаручым.

* * *

Тагын бер ничә көннән соң, очраштык. Ул миңа татар җыры дискларын тоттырды. Матур йомшак уенчык бүләк итте. Мин алдым, бу уенчык минем иң яраткан уенчыгыма әве-

релде. Ул гаҗәпләнде минем тиз генә бүләкне кабул итүдән, тик күрсәтмәде, йөзен дә чыгармады.

Бу көнне без Бауман урамын айкап чыктык. Без бер кафедә ипләп кенә сөйләшеп – гөрләшеп утырдык. Монда мин танышларны күрдем – алар артистлар иде. Ул аларга диск калдырып, бүләк итте. – Теләсәң, менә фәлән – фәлән җырчы кыз аранжировчикның сөяркәсе, кемнеңдер акчасы бар, кемнедер ирләре йолдыз ясый.

– Мин синең сөяркәң булмыйм!!! – аның тел төбен аңлап кырыс әйттем мин аңа. Бөтен жаным – тәнем белән каршы булам мин бу карашка.

– Дура.

Мин эндәшмәдем. Ул миңа тагын сорау бирә:

– Айның ахырында Үзбәкстанга поездка була, барасыңмы?

– Карарбыз.

“Мин әле саф, гыйффәтле кыз” дидем аның колагына тавышланган Бауман урамында оялчан тыныч тавыш белән.

– Ничек алай, сиңа бит 21 яшь түгелмени? Ә, мин үзем дә беренче тапкыр 20 яшьтә 16 яшьлек кыз белән булган идем, диде ул гади бер нәрсә турында сөйләгән кебек.

– Әйдә, арена дискотекасына барабыз, дип мине алып китте. Арена дип аталган бөтен шәһәрнең яшьләре бии торган күңел ачу үзәгендә минем кызганычка каршы булганым юк иде әле. Бу бина чынлап та бик матур икән шул. Кып – кызыл йомшак итеп эшләнгән калын диваннар, бильярд залла-

ры, заманча музыка һәм сыра, сок, аракы, төрле шәрабләр тулы “бар” лары белән һәрбер монда кергән кешене үзенә тартып тора.

Анда килеп керү белән ул миңа болай диде: “Бөтен егетләр синеке, ә кызлар – минеке”. Җавабымда – көлү, елмаю булды. Тик бер – беребездән китә алмадык. Аренадан чыккач, өй янына кадәр ул мине озатып куйды. Без тагын шашып – шашып кочаклашып үбештек. Алдагы көннәрдә очрашырга сүз куештык.

Мин өйгә кергәч тә әле, бу хисләр эчендә йөздем. Төннәр буе йоклый алмыйча, аны гына уйлап уздырган татлы мизгелләр әле дә онытылмый.

* * *

Бер көнне ул мине үзенең эшенә чакырды. Бу эш урынына гади генә кеше керә алмый. Анда керер өчен телефонын белеп сәркатип кыз белән сөйләшеп ниндидер тәкъдим ясарга кирәк. Эшеннән икебез бергә чыктык та, ул миңа сыраханәгә иптәшкә барырга тәкъдим итте. Киттек.

Бармен белән икешәрләп кыстадылар мине вино эчәргә. Ул үзенә туп – тулы кружка сыра салдырды. Мин ризалашмагач, Әнвәр миңа мин сораган чәй китерде: мин аны яратуга тагын бер адым булды. Кинога барып, анда “Мәхәббәт тарихы”дигән кино карадык. Без инде яшьләрчә иң соңгы рәтләргә утырдык. Кино караган чакта, күзләргә яшь чыгарды.

Шунда ул үзенең ирләр коралын күрсәтте, мин гаҗәпләндем, кыскача-дура булдым да куйдым шул вакыт! Мин курыктым, чөнки мин хәзер тагын да күбрәк аның колы буласын сизә идем…

Кинодан чыккач ул миңа минем белән барасыңмы диде үзенең каты, башымны әйләндерергә юлын алып барды. Мин инде аннан бер генә секундка да аерыласым килми иде. Без бер машинаны туктатып, ул чакырылган җиргә киттек. Миңа барыбер иде ул кая алып барса да. Тик калдырып кына китмәсен иде мине. Килеп җиттек медицина университетыннан янындагы кафега. Анда безне бер ир белән хатын каршы алдылар. Шуннан Әнвәр 1,5 литрлы сыра сатып алды да без барыбызда медицина университеты бинасының артыннан бер подвалга кереп киттек. Ул мунча булып чыкты, аның саунасы һәм 2 коену кабинасы бар. Мунчада безне тагын урта яшьләрдәге бер ир каршы алды. Мунча алдында имәннән эшләнгән зур түгәрәк өстәл тора иде. Әнвәр сыра шешәсен шунда утыртып куйды. Урамдагы киемне салып, өстәл артына утырдык. Өстәлгә урта яшьтәге ир -

мунчаның бүгенгә чакыручы стаканнар, закуска китереп утыртты. Ирләргә стаканнарга сыра салып куйдылар, ә безгә аларда булган виноны салдылар. Әкрен генә сөйләшү китте. Бишәү утырабыз. Минем иң беренче күзгә чалынган нәрсә шул булды, бу ирнең бөдрә чәчләрендә бер урынында чал чәчләре күренә иде. Үзе озын буйлы. Безнең белән килгән Николай түгәрәк өстәлнең икенче ягында утыра иде. Теге ха-

тын аның янында утыра. Әнвәрдән башка егетләр җиңел наркотик иснәргә тотындылар. Миңа кызык иде: туганнар авылында абыйларның апаларның алар үзләренең авылларында мәкне чиләк- чиләк җыеп, рәхәтләнеп ашап, колхозга тапшырулары турында сөйләгәннәре искә төште. Ә балачагында җәй көннәрен бергә үткәргән энекәшләр әйткәннәр иде анашаны ашау турында.

Әнвәр миңа әйтте: “Мунчага егетләр – егетләр белән; кызлар кызлар белән керә диде”. Мин ышандым. Тик мунча керер вакыт җиткәч, Николай теге яшь хатын белән кереп киттеләр икесе бергә. Мин шаккаттым, Әнвәр дә шаккаткан кебек булды. Әммә без бер сүз дә дәшмәдек. Өстәл артында өчәү утырып калдык. Альберт сорады Әнвәрдән:

– Сиңа ничә яшь?

– Әнвәр – 28 диде.

– Балаларың бармы соң?

– Юк диде.

– Син бу кыз янында гына булганга шулай дип әйтәсеңме?

– Юк, диде Әнвәр.

– Ә минем инде ике балам бар, диде ул. Мин аларның нәрсә турында сүз алып баруларын игътибар белән тыңламадым да. Миңа әйткән алдау бер үк.

Без әле вино эчеп утыра идек, мунчадан теге ир белән хатынның җенес мөнәсәбәткә кергән вакытта була торган ләззәтләнгән, иркәләнгән тавышлары ишетелде. Без озак кына аларны көтеп, көлеп утырдык. Алар чыккач, Әнвәр миңа:

“Анда ак җәймә бар, бар кереп чишен”, диде.

Әнвәрне чынлап та җайсыз хәлдә калдырмыйм инде дип, мин дә кердем мунчага, тәнемә җәймә ябып. Әммә Әнвәр тәнемә ябылган җәймәне куллары белән ипләп – ипләп шудырып төшерде… Калганын да… (Кыскасы, бөтен нәрсәне, яман – татлы төш сыман хәзер таныйсы килә.) Ләкин мин бирелмәдем аңа. Кем кемне күбрәк назлагандыр үзе аңлар һәм үз намусында калсын.

* * *

Өйгә кайткач Әни юеш чәчләремне күреп, миңа җанҗал ясады. Шунда ук миннән аның инде онытып алган телефон номерын сорап алды. Бу шимбә көн иде. Берсе көннән үк әни аңа шылтыратырга булды.

Дүшәмбе көнне, мин эштән кайткач- җиделәрдә, өстәлләрдә пироглар, тәм – томнар, җимешләр тора иде. Тик өйдә беркем дә юк. Мин компьютер янына утырдым, тагын танышулар сайтын ачтым. Ишек йозагы ачылган тавыш ишетелде. Кергәч, әни әйтеп өлгерде бездә кунаклар диеп.

Әни әле тышкы өс киемен дә салып өлгермәде, ә Әнвәр инде зал ишегендә күренде. Мин тиз – тиз интернет сайтларын ябырга тырыштым. Тик җитешмәдем. Ул инде минем алдымда булды, күрде нинди сайт ачылганын.

Әнвәр шул мәлне әнигә әйтте:

– Ул әле егетләр эзли, каян ул бездәгеләргә.(Имеш, аның

тел төбендә мине яулап алу мөмкин дә түгел.) Ашадык, эчтек. Мин аны озатырга чыктым.

– Ярый. Бу безнең эштәге роман булыр, күзләрне сикертә-сикертә, диде ул миңа. Мин бу сүзләргә нәрсә әйтергә дә белмәдем. Үземә бикләндем. Ул үзенә кайтып китте.

* * *

Берсе көннән икебез татар дискотекасына барырга җыендык. Килдек кичке 9, анда ишек ябык, кешеләр юк иде. Без уйлаштык та, ул мине вокзал ягына таба алып китте. Мин билгеле, каршы килмәдем. Без кая? Каядыр китәбез?сорап кына куйдым мин. Ул елмайды. “Бәлки икенче клубтагы дискотекага барабыз?” Мин билгеле андада булмадым. Шатлык белән: “Әйдә!”. Бу көнне ТИСБИ университетының беренче курслар кичәсе булып чыкты. Миңа әллә ничек кызык булмады үзем чыгарылыш курсларында булганга. Ул монда үзләренең электәге хезмәт-танышларын очратты. Минем китәсе килә башлады. Тик ул диде: “Китсәң – бер үзең китәсең”. Аннан әзерәк торгач, бергә кайтып киттек- мин үз өйемә, ул зур апасы һәм песие булган өенә.

Иртәгәгә концертка барырга сөйләштек. Мин яраткан кара чалбарымны кидем. Институттан йөгердем бар“ Beerloga”га. Шул чакта минем чалбар теккән җиреннән сүтелеп китте. Анда ул мине көтә иде. Тәрәзә кырында чәчкә – кызыл роза ята. – мин “коры” гына “Рәхмәт!” (Бер дә

кирәкми иде уйларым, йөрәгем киресенчә-җанланып китте) Тирәдә берсеннән берсе матур кызлар утыралар иде. Әнвәр дә, мин дә күзләп чыктык барысын.

– Шундый күп кызлар! – гаҗәпләнеп дидем.

– Син шундый бай кызлардан түгелмени?

– Юк шул, тәтемәде безнеке шикелләргә.

– Мин дә, менә әле генә йөри башладым мондый заведенияләргә.

Гадәттәгечә, аның чакыру билетлары бар, концертка без әзгә соңлап килдек. Буш урыннарга утырдык. 1 бүлеге бетте. Мин Әнвәр белән беренче очрашкан көнне кешене күреп калдым. Әнвәр аңа сәламләшергә китте, арттагы чалбар кесәсеннән тулы пачка акча күренде. Ой, миңа нинди кеше эләкте, дип шатландым. 2 бүлектә чакыру буенча урыннарыбыз шул куркыныч кеше белән янәшәдә. Утырабыз сулдан уңга: Әнвәр, мин, Айгөл һәм ул.

Мин Әнвәрнең колагына сорыйм: “Бу Радикның кызымы?”

“Хатыны” дип ташлап куймасынмы шунда… Мин аның хатыны юк дип уйлаган идем. Дәрәҗәле урында утырам икән мин үземне хис итә башладым, чөнки мин дә бит Әнвәрем белән утыра идем. Ә-әй, юләр баш, эх, юләр чак… Кайткан юлда Әнвәр босcның иностраный машинасында килдек. Ул мине озатып куйды өйгә хәтле. Хисләр ташый иде.

* * *

Бер көнне балалар бакчасында концерт куяр вакыт, ул бит миңа эшемне бүлдереп, шылтырата, менә сиңа вәт; “Ярар, килермен” дип куйдым. Ул мине җиденче яртыда “Suvar” кинотеатрында көтә икәнен әйткән. Мин 6 сәгаттә әле үземнең өем кырында, утырдым бер маршруткага, шуннан күрәм, күпер инде ярты юл да үтмәенчә, вакыт инде 20 минут җиденче бәрә. Мин маршруткадан чыктым да, тизләп машинаны туктаттым. Шулай 25 минуттан килеп җиттем.

Тагын бер концерт барырга сөйләшеп куйдык та, бәйрәм көннәренә ул мине әнигә әйтмичә генә үзе белән ял итәргә чакырды: кочаклашырбыз әзерәк. Әнигә син “дуслар белән барырбыз” әйтерсең дип, өйрәтеп җибәрде. Үзем дә гаепле. Тик язмыш шулдыр..

* * *

Без ике бүлмәле фатирда торган чагыбыз: абый, килен, 1-2яшьтәге аларның баласы, әни, мин. Апам, кияү балалары белән Уфада. Шул мин Әнвәр белән киткән чагында бездә атна буе 8 кеше яшәде, мин, ахры, күп кешеләрдән киттем, түзәлмәдем. Хәзер абыем зур өй сала Казан тирәсендә. Әз – мәз кодагыйлар булыша.

Бер – беребезгә әле ышандырырлык кешеләр түгел идек, курку бар арабызда. Аның, әлбәттә, бигерәк төрле якларга барган җаны. Әмма аның куркуы һәр тән хәрәкәтеннән киле әле дә. Без “Бәхетле” маркетында янында очраштык. Сәгать 2 яртысы иде. Ашарга алырга кергән идек. Барып анда ашарга. Ул ике сумка тутырып ашарга алды: иң тәмне, иң кыйммәт ризыклар. Шуннан ул такси алдан яллаган. Без утырдык, кулларыбыз бергә булды. Күп кенә юлны үткәч, әз гәҗапкә калдым. Әнвәрдән сорагач, ул әйтте: акча ага – күп инде, карале 600 сум бит тула. Урынга килгәч, такси җибәрдек тә чыктык урамга: саф һава үсеп торган наратлар. Зәңгәр күк, беренче кар ява иде – бигрәк матур күренеш. Әнвәр ике номерны сайлаган да мин ике кровать булган ике бүлмәле номерны сайладым. Кергәч, чәй эчтек лимон белән. “Әйдә кочаклашабызмы?” Мин шатлык белән аңа ашкындым. Барысы шундый матур иде. Гүзәллек, сокланырсың. Шушы мизгелләр без назлаулардан тыныбызда кала язган, ахрысы. Шуннан без вино эчтек. Тагы бу вино! Аллаларның эчемлеге!!! Нәрсәгә үпкәләргә соң?

Без яттык. Кочаклаша-кочаклаша, үбешергә тотындык. Мин элек чишенгән килеш тә: эчке кием – трусикта, бюстгалтерда егетләр белән кочаклашканым бар иде, гәебемне сизәм. Тик иң кыйммәт урынны бер кешегә бирмәдем, имеш, акыллы. Монда да шулай булып өметләнә идем. Мин аны сорадым: “Син алдамыйсыңмы?” Юк. Без ләззәткә күмелдек. Аннары ул шундый назлы, үз булдыклыгын тойган тавыш

белән: “МИ – НЕ – М”.

Нәрсә соң ул страсть – шашыну? Татарларга хасмы бу сыйфат?

Хастыр, “Все мы ходим под Богом” урысларда әйтмешли.

Шуннан яттык та, ул минем эчке киемне салдыра башлады, башта әз генә, каршы килгәч; тик күңелләр дә, тәннәр дә кушылырга теләделәр. Эш беткәч … Мин аны кулыннан сыйпадым. Ул диде: Рәхәт, ләззәт. Син минеке, диде ул. Кайттык шәһәргә. Саубуллаштык.

Тагын бер көлкеле мизгел булды. Без бассейнга барырга җыендык та, ул 40 минутны арендага сатып алды. Анда бассейн зур түгел иде. Ләкин әз генә көтәргә туры килде. Шул бассейнда 4–5 кыз чумдылар, йөзделәр, күңелле итеп вакыт уздырганнар. Көттек – көттек тә, безнең вакыт килгәч, Әнвәр әйберләр капшап карагач: “мин трусикны өйдә оныттым” – диде. Мин көлеп җибәрдем. Ул китте трусик артыннан, ә мин бассейга чумдым. Ул барып – килеп йөргәнче 20 минут үтте диярлек.

* * *

Көтеп алынган мизгелләр дә килеп җиттеләр. Әнвәр әйткән иде, без 7–8 кыз белән утырачакбыз. Минем әни эшеннән билетны алды. “Татар җыры” концертының биш көннән бересе.

Янәшәмдә минем белән олы гына хатын утырды. Олы дип

әйтү генә – 40–50 яшьлек, аера алмыйм. Аның белән сөйләшергә әллә дулкынлану, әллә куркудан көч булмады. Аннан бу хатын шундый назлап, йомшак тавышы минем колакны тетрәндерде: Ә – Н – В – Ә – Р..! шул вакыт үлдем дә киттем: әллә ул аның апасы, әллә тетясы. Кем белер. Бер сүз чыгаралмадым. Әнвәр кырына кыз утырды. Әнвәргә бәйләнә башлады. Ул яшь җырчының сеңлесе булып чыкты. Без утырдык сулдан – уңга: хатын, мин таныш кыз – әле җырчы тугел, Әнвәр һәм теге кыз. Бер мәлне теге кызның куллары кушылды. Мин югалдыммы, – бу чын – чынлап көнләшү булды. Антрактта сатып алдым чәчкә яңа яраткан җырчыма диеп. Тик җырчының беренче номер булып концертта әллә нинди җыр җырлады да, халык та чапмады җүнләп. Бирми калдым соңыннын, таныш егетләргә берәр чәчәк бәйләмен икегә бүлеп, чыгып, аларга тараттым.

– Малайларга!

Концерт беткәч, мин тыныч кына чыгып киттем. Ә әни саубуллашып китте. Икенче көнгә ул концерт барышында 2 билет бирде.

* * *

Иптәш кыз белән бардым, тик ул татарча ныклап аңламый. Ул үзе скрипкада бик сыйфатлы, югары дәрәҗәдә уйный белә. Һәм җырларга да нечкә матур тавышы үзендә бар. Бу көн – олы шәхесләр көне иде. Безгә – яшьләргә бик кы-

зык булмады.

Әзерәк таныштырырга булдым. Концерт ахырында аның кырына килдек. Иптәш кыз Алина: “Бу нинди чувак?” дип соравды. Минем әйтәсе килде: “Бу тик минем чувак.” Дәшмәдем.

Әнвәр сагынып беткән шикелле чакырды. Барабызмы ялга, клубка бәлки Мәскәү егете белән таныштырам. “Әй, Миша, барасыңмы? Бу менә исеңдәме, Земфираны җырлаган кыз”. – Ә – әйбәт, әйбәт, дебют өчен тагын да, диде бу Миша. Шунда ук Земфираның “Телисеңме?” җырын копиясын ясаган аранжировщик та барды. Компания 6–8 кешедән булырга тиеш иде. Тик клубка 5 кеше барып җитте. Мине Әнвәр тагын кисәтеп куйды: “Мин берүзем”, дип, үпкәм калды әзгә. Тик шул чак минем арттан теге Мишасы чаба башлады. Мин белдем фамилиясен. Кем булып эшли, хоббины. Яшь җырчының сеңлесе аранжировщик белдән дуслаштылар. Килгәч, Әнвәр үзенә игътибар итү өченме, акчаны туздыра башлады. Тагын ике кызны эләктереп, эчә башладык. Исергәч. Миша белән үбешә башладым, Әнвәр икесен үбә. Төнге җеннәр. Без биергә тотындык. Мин үземне җиденче күктә хис иттем. Үзе чибәр. Йомшак сүзле… Әнвәрнең телефонын урлаганнар. Әнвәрнең кәефе тәште, мин Миша белән биегән идем. Ул бер сүзсез чыгарга юл тотты. Мин күрдем, рөхсәт сорап, йөгердем китеп барган юнәлештә янына; кочаклап. Аннан гафү үтендем. Ул әйтте: “Мин үзем гәепле”. Минем дә кәефем кырыланды. Мин күз астыннан карап, елмайдым аңа.

Танышуны дәвам иттек. Тик ул миңа бер сүз әйтте. Аннан соң, акчаны бик чутлый торган кеше иде. Икенче көнне мин Әнвәрдән китмәскә тырыштым.

– Нигә янына бармыйсың?

– Ул минем хыялым булды һәм ул чәлпәрәмә төште, сирпелде, китте.

– Ни өчен?

– Ул миңа әйтте.

– Ә мин әле әйтмәдемме әле?

– Юк. Син әйтәлмисең ансын.

– Нәрсә соң ул – әйт.

– ЮК.

Соңгы көненә билет бирмәде. Шулай көннәр узып барды. Мин җырны өйрәнә тордым.

Аның туган көне дә килеп җитә. Мин дә аңа бүләкләр биргәләдем: я йомшак эт озын аяклар белән ак төстә кара таплар белән – далматин; перчатка кара – мин синеке диеп. Ул мине тагын да бер үзен калдыра, чакырмыйча. Мин үпкәләүдән бөтенләй сүзсез калам. Ул миңа: компьютер өчен күп кенә әйберләрне; соры уенчык песи, косметик набор "Dove" дигән. Аның матди бүләкләре миннән кыйммәтрәк булдылар да бит, ярышмадым да, рух дигән нәрсәне ул миннән күп вакытка алып китте. Әни сизеп, мине әти, апа янына туган шәһәремә җибәрә ял итәргә. Акчаны да синтезаторга этидән алырга. Булса тагын, компьютер частьне алырга әти эшеннән.

Аннары мин белдем аның биографиясен кайбер белдерүләрне. Улы 9 яшлек бар иде, песие җирән төстә. Әйткән иде, сеңелнең кызы, ә ул аның кызы булып чыкты. Бер хатын да бар иде. 3 фатирга керә ала, яши ала. Кайсысы үзенеке, ул, ахры, үзе дә белми.

Шулай көннәр узды. Җыр язылу көне килеп җитте. Ярыйсы, әйткән звукорежиссер. Әнвәр сорады: "Ә бу нәрсә?" Кыскача, аңа ошамады: кирәкмәстән әйбәт булды. Мин сәхнәгә дә чыкмадым. Миңа ул тагын бер җырны бүләк итте, февральнең башында биргән Авызов аранжировщикка дигәнен.

* * *

Миңа үземә әллә нинди исем кушканнар бит, ошап бетерми идем. Сәбәпләр дә булганнар, ахры.

Хәзер, иң асылына барып җитәбез. Мин балалар бакчасында Андрей исемле малайны ошаткан идем, тагын Марат дигәне бар иде. Ә Вовага без иптәш кыз Салимгәрәева Женя бнелән аңа бер мәлне тархуннан крышкаларын ыргыттык урамда йөргәндә. 1 класта Диас буйга бәләкәй, тик акыллы. Дүртенче класта Роберт исемле малайны ошаттым, ул 8 мартта туган ир бала. 6 класта Алексей Коряковцев миңа 6 – 7сыйныфта, яртысын 8 класта күз ата иде, хәтта валентикалар җибәрә иде. "Бөркет" лагерьгә баргач, аннан соң ярты ел уйланып Артем исемле малайны ошаттым, ул Архангельск төбәгеннән иде. Казанда тагын Артем дигән егет бар

иде. Безгә аның белән үбешергә кыюлык җитмәде, бик ошатып йөрдек бер – беребезне.

Аннан соң, 1 курста укыганда Альберт Николаевич исемле егет белән таныштым. Барысы 6 очрашу булды. Концертка бардык та хат языштык. Тик аны мин сагынган чаклар булды инде. Тагын беренче курста мин бер егетне очраттым: ул миңа бер дә ошамады, тик ул үлеп йөридерие. Бәлки, улдыр минем язмышым?!

Балачактан ук музыка белән шөгелләнгән кеше үзем. Үсешем ирекле булган, тыймаганнар, иркәләп үстем, әти – әни аерылган булсалар да. Миңа 3,5 яш булганда, алар аерылганнар, тик тазалыкка зыян китерде бу хәл – минем (тән) аллергиядән нейродермитка күчкән авыру. Тик ул бик нык эш белән мавыксам гына чыгадырые. Минем бертуган апа белән абый да бар. Алар аерылуны ныгырак сизгәннәр, бөтен авырлыклары абыйга туры килде, чөнки 14 яшеннән эшли башлады, әнигә зур terәк булып. Әнинең үсмер яшеннән үк хыялы булды – Казанда яшәү. Миңа 15 яшь тулганда, без Казанга күчеп килдек. Мин укуымны шундый ук махсус музыка мәктәбендә дәвам иттем. Фортепианода бик яхшы итеп уйнарга өйрәнергә исәп бар иде. 4–6 сагәть пианино алдында утырырга укытучым таләп итте. 2 ел әйбәт итеп өйрәнүдән соң, ресторанга урнаштым, тик укытучыга әйткәннән соң, аның мөнәсәббәте миңа үзгәрдә. Мин аны гафу итәлмәдем: 10 класстан бер елда ике уку елын бетереп пед факультетка керергә тәкъдим иткәннәр, әлбәттә минем теләкләремә

таянып. Чөнки мин җырларга теләдем яраткан укытучыда. Сәламәтлекне ныгытырга да җырга өйрәнергә теләгем иде. Гомумән алганда, ирекле булырга, чөнки миңа анда җайлы иде: күпчелек вакытта мин үз —үземә бирелгән идем. Монда татар мохите дә күберәк.

* * *

Мин, җырчы буласы кешегә, больницага тамакны төзәтергә яттым.

Больницада телефон трубканы алдым да Әнвәремә: “Кайчан киләсең?”

– Кичә генә очраштык. Син сагынып бетмәдең бит әле.

– Шулайдыр. Ә кайчан килерсең?

– Әйдә, бер—ике көннән соң килермен.

– Ярый, көтәм.

Ул көнне аны “Йолдызлык” фестивалена чакырдылар. Ул килде шимбә көнне иртән. Унга сөйләшкән идек, ул унынчы яртысына килде. Мин әле лечениядә, тиз генә чыктым, шул ук вакытта бәдрәфкә чыгасым килде. Аңа ун – унике минут көтәргә туры килде. Нигә озак сорауына, әллә нәрсәне уйлап табып, җавап бирдем. Залга төшкәч, ул уртада басып тора иде, бердә шулай басып торганы булмады. Мин үпте бөтен хис белән, тотына башлады миңа. Мин алып киттем аны зал кырына. Шунда күчтәнәчкә алма, алма согы, CD, ике журнал, әз генә акча тапшырды.

“Мине чыгаралар бүген” дидем мин. – “Ничек, сине бит җомгада чыгарырга тиеш иделәр, түгелмени?” “Менә чыгаралар инде, кокетливо әйтеп җибәрдем.” Сикунд… “Барасыңмы бүген дискотекага?” (шул сорауны көттем бит мин) “Барам, әлбәттә!”

Матур күлмәкне киеп, очраштык. Өй… Өйгә, аның өенә беренче кайтып килү иде. Чын ләззәт, бәхет, чын назлы сөю, әнә шундадыр булды минем тормышымда.

Җәннәт бакчасы һәм бәхет.

* * *

Кәеф төшкән кебек булды, андый хәлсез чакларның берсе; алтынчы яртысына эшенә килдем. Сагындым, сәламләштек тә, утырдым. Тынлыкта утырдык. Хәтергә соңгы өйдәге төн керде. Без чыктык эшеннән. Ул сыраны эчте дә, әйдә киттек, диде. Ә мин аңа CDта биргән идем 6 демо, эшкәртелмәгән җырларым белән.

“Әйдә” кырт кисте ул. Без автобуска утырдык. “Алтын Урда” ресторанына кердек. Анда татар дискотекасының “Күңел” ачылуы. Әз генә барда утырдык, дискотекага төштек. Мин алып баручы уенында катнаштым. Шуның катнашучысы-бер малай танылган шәхеснең дусты иде. Ул мине биюгә чакыра башлады. Бу күренешне күргәч, Әнвәр яшь кызны биюгә чакырган. Мин дәшмәдем. Тагын ике егет биюгә чакырганнар иделәр. Караңгылык төшкәч, чит кешеләр

китеп беткәч мин аны беренче залда – коридорда көттем. Егетләр үзләре белән чакыралар. Ул озак кына көттерде, 20–25 минутлап – анда акчаны бүлешкәннәрме, әллә юри – мине сынатыргамы, белмим. Шулай, без солист группаның машинасына утырдык һәм поклонницасының туган көненә киттек. Әнисе әйбәт кенә. Безне 6 кешене каршы алды, сыйлады. Төнге икенче яртыларда Әнвәрнең телефоны SMS килде “Мин сине яратам” Гөлназ. Минем чәчләрем дымландырдай күтәрелде, тик йөземә чыгармадым. Ул шылтырата аңа. “Нигә йокламыйсың?” Шул сүз булды, әлбәттә, яхшы интонация белән. Җырчы калды алар белән, безгә дә тәкъдим иткәннәр иде. Әнвәр миннән сорады. “Калабызмы?”. Анда өч бүлмәле фатир иде, бөтен кунакларга урын булыр диярлек. Мин: “Юк” (шешенденңме әллә? башымда фикер очып үтте) кына әйттем, әз генә үпкә калды шунсына.

Урамда яңгыр коя иде. Барып җиттек подъездына, ул ачкычны оныткан икән. Домофонына төнге 3 тә күршеләрне уятырга туры килде. Тагын 8 катка менгәч, тирәдә яшәгән күршесен уяттык та, ул бабай булып чыкты. Мин күренмәскә дип уйладым. Тик ул ишекне яба башлады – мин ишеккә тотындым. Ул мине күргәч, Әнвәргә әйтте: “Тагын хатыннарны җыясың – Судка бирәм мин сине! Бурсыды ул.

Яткач, миңа рәхәт иде. Ул минем янәшәдә. Ул теләде, мин үземчә “буйсындым”, тик бу хатыннар турында хәбәр безне икебезнедә суытты. Арыдык та әле, йокладык.

8 иртәнгедә уяндык. Беренче тапкыр ишеттем һәм аңла-

дым. Аның телефонына хатыны шалтырады. Ул хатынга “әкият” сөйли башлады. Мин уянган килеш булдым ләкин сиздермәскә тырыштым. Бәлки ул да сизгәндер, ничектер ул усаллык белән миңа кагылды. Мин каршы килмәдем. Ә шуннан тиз, киендем дә ычкындым. Шунда мин үземне чын – чынлап хур кызы дип санадым. Миңа институтка барасы бар иде иртән. Тик мин өйгә кайткач, яттым. Хәл бөтенләй юк иде.

* * *

13 май. ҖОМГА.

Өйдә ызгышлар күбәйгәннән күбәя барды.

Бер көнне әни белән ачуланыштык, Әнвәр турында сүз кузгаткач мин әрнүдән киттем аның кырына, күңелдә ул мине җанландырыр дигән өмет бар иде.

Тик шылтырата башлагач ул трубканы алмый. Мин аңа SMS җибәрдем: “Мин сине көтәм, өең кырында”. Ярты сагәть үткәч, мин бардым шәһәр тыкырыгына. Анда агач астында йомшак үләнгә чүгәләп машина узганын карадым.

Утырам:

Ахырга иде монда калып җептә асылынырга. Мин аңа “хуш” дип SMS җибәрдем. Соңыннын шылтырата башладым. Ә ул… Ул: ну и ради Бога! Мин көлеп җибәрдем, гаҗәпләнүдән. Аңыма һава кергәндәй. Шулай мине юмартлык коткарды үлем теләгеннән.

Барыбер аны күрәсем килгән иде. Кочаклашасым. Менә шулай китеп бардым аның фатирына. Башта янында торырга уйлаган идем, куркып – куркып мендем 8 катка, кулны звонокка суздым. Тотынган шикелле дә булмадым. Ләкин шылтыраттым икән. Ул ачты ишекне. Башта ишектән башны чыгарды. Ә соңыннан бөтенләй үзе чыкты. Ул вич чишенгән килеш, шәрә басып тора иде. "Әниеңә шалтыратам, акылдан яздың мәллә? явыз диде ул.

Мин юри китмәдем. Тора идем генә.

"Бар әле, тиз әниең кырына кайт". Бүлмәдән аяк атлавы ишетелде. Мөләем хатын – кыз тавышы ишетелде: "Кем бар анда?"

"Юк, адашканнар" диде Әнвәр.

Хәлне аңдагачтан, мин тиз йөгереп төштем. Еларга тотындым, бер кем тыялмаслык. Һәм өем таба җәяүләп җыендым. Җылый – җылый китеп бардым, нәкъ Илсиянең "18 яшь" җырдагы шикелле. 15 машинаның йөртүче егетләре миңа утырырга тәкъдим иттеләр. Беләсездер ни өчен. Менә безнең шәһәр әхлагы. Мин билгеле, юл урамы буйлап бардым. Шуннан иртәнге 5 тә тукталышта хәл җыярга утырдым. Машина узычы йөртүче күреп калгач, туктады да, мине кайда кирәк шунда илтеп куярга тәкъдим итте. Чибәрлеккә чамасыз ир булды. Мин кинәт "юк, рәхмәт" әйттем. Менә шулай, җәмагәть.

Ипләп кенә күпер янында 6 сагәтькә килеп җиттем өйгә, йокларга. Битем ак, үләксә төсендә иде. Постельгә ташлан-

дым.

* * *

Ә без талашканнан соң, мин җыендым чит илгә китәргә. 4 ягым кыйбла дигәндәй. Китә алмәдем.

Ул үзе икенче көнне үк китте Крымга ял итәргә, тик таныш кыз әйтте, ул бик ачулы килде аннан. Аннан соң ике туй узды, тагын бер пар кушылышты: берсе аранжировщик иде, берсе Әнвәрнең офисында сәркатип булып эшләүче кыз.

* * *

2 август.

Кич мин аны эш янында көтеп тордым. Махсус, алтынчы яртыга килеп җиттем һәм утырам эскәмиядә. Иң матур киемнәремне киеп – теккән күлмәк белән былтыр модада булган ак кыска чалбар.

Ул 15 минут җиденчедә эштәге крыльцога чыкты да, карап тора – кайсы якка бырырга дип. Миңа шулай итеп тоелды да күренде дә. Ул кызыл майка кигән һәм яшелле-сорылы җиңел чалбар. Һәм минем якка юнәлгән. Ул мине, әлбәттә күрде, һәм күрмәмешкә салышып, үтәргә тырышты. Мин аңа: "Сәлам!" Ул да шулай җавап бирде. Мин аңа сөйләшергә тәкъдим белән дәштем. Гафу үтендем. Һәм мине кочакла-

шуын сорадым. Тик ул бер дә teләк белдертми. Ул миңа: “Нәрсә, үтерәсеңмени мине, кочакламасам?”

– Юк… гомереңне бозам!”

– О – го! Ярар! Кил… Әйдә. Җитте, безне күрәләр бит. Булдымы? Күңелең тулдымы?

– Әйе. Ә, юк. Син Чыңгызга берәр нәрсә әйттеңме, нишләптер ул миңа язалмый фанерасын?” Фанера – ул җырның аранжировкасы, шулай дип әйтергә күнегелгән инде.

– Юк, бер нәрсәдә әйтмәдем!

Мин киттем.

Бу уен башланды.

Сызланам, эш поша. Уйлар яңа, тормышка яңа карашлар үзгәрүе, ностальгия, ретро.

* * *

Бар шундый әйтем халык сүзләреннән: Үзеңнең хатының белән сәясәтъ турында сөйләшә аласың икән, син бәхетле ир кеше. Тапшыргач, бик үк яхшы язылмаган җырны, телефон аша сөйләштек.

– Тыңладыңмы? – Тыңладым. Архивка керттем. Ул ачу килде дә инде шушы сүзләргә. М – м, дидем. – Сорауларның юкмы башка? – Бар! – Нәрсә турында? – Сәясәт. – Нәрсә? Сәясәт… Коммунизм әллә качан бетте. Бердәмлек тә бар “Регионы – вся Россия”! – М – м. Ярар. Бу сөйләшү Салаватның “Бүре” җыры чыкканнан соң. Шунда мин аны белдем,

без уйлар белән якын икәнен.

* * *

Аннан, ул миңа бүләк итеп мин бөтен тәнем җырлаган җырны икенче җырчыга биреп, җырлатып, 29 август көнне радиодан җибәрде. Мин ике көн елап йөрдем. Безгә әле Санкт – Петербургтан танышларыбыз килде бөтен гаилә белән – алар инде бөтенләй дингә бирелеп яшиләр. Мәчетләргә йөри биш баласы белән бергә..

* * *

Ноябрь.

Мин аны шундый сагынган чак иде. Көндезге аш вакытына очрашырга килештек. Мин ярты сагәть алдан килдем. Ул вакытында килде, тик итекне яңасын кидем. Ул да уйлары белән күберәк эштә кебек тоелды. Без ипләп кенә тынлыкта утыра башладык. – тагын бикләндәңме? А то, китәм хәзер. Ни өчен чакырдың мине? – Тынычлан, башта алып килсеннәр ашамныкны. Соңыннан, ипләп сөйләшә башладык. Хәтирәләрне бераз сүттек. Киендек. Тәннәр бер – берсенә тартылалар иде, тик үзебезне кулда тоттык, Мин аннан сорадым. Ярыймы синең белән? Әйдә, култыклап киттек. Эх, тоясы иде тәнен. Яратам да инде бу кешене.

– Тишек, тишек, тишек.

– Нәрсә? Мин аңламыйм.

– Ничек инде?

– Син мине бит үзеңә алмыйсың эшкә? Ни өчен миңа аны өйрәнергә, әйт?

Ярый, без базар янынннан үтә идек. Анда этләр бик матур сатылалар, берсе лабрадор көчеге иде. Мин абыем белән үткәндә, шул ук этне күрдем һәм сорадым ничә сум дип. Безгә әйткәннәр: 16 мең. Мин Әнвәргә әйттем:

– А – һа, ул әнә 16000 тора. Мин хәзер синең уенчык песикәең белән йоклыйм. Шулай юллар өзелгәндә, ул кулны болгарга җыенды гына. Мин әйттем, “Юк инде, нишләп? Ә кочакларга?!” Ул мине үзенә таба китерде дә кочаклавыннан сыта язды, сөякләрем чыңлаганнар. Без хушлаштык.

* * *

АРЕНА. 28 ноябрь.

Арена – казандагы төнге клубларның үзәге. Әнвәр (ул генә түгел инде, билгеле) дүртенче мәртәбә анда татар дискотекасын уздыра.

Билетны миңа Әлфия дус бирде. Димәк бушлай кердем. Мин дус кызым Элеонора белән уйлаган идем барырга. Тик, ул кәефе төшенкелегән дәлилләп барырга ризасызлык белгертте. Минем күңелем китте, рәнҗедем дип тә, әйтеп була. Менә инде дискотека башланды. 20 минуттан кердем, танц-

полда кызлар тулы. Егетләр дә күренгәли. Эзләдем, табалмадым. Бер кызыл диванга утырдым. Кызлар бииләр, музыка колакларны бәрә. Ул минем алда үтә, башны күзләргә карамаска тырыша. Җыласыларым килде. Күңеле әле нык дип, бастым: сәхнәгә Гөлназ чыкты: күлмәге алтын төсендә мини – күлмәк, сапоги да махсус тегелгән шул ук алтын тукымадан. Артында 3 малай бии. Шуннан "Очрашу" җырын куйды, шуннан егетләр дуэты "Бердәнберем" дигән җыр җырлап тапшырдылар; менә яңа яшьләрдән яшь җырчы чыга Пума исемле. Ул килде кызыл күлмәк (нәкъ минем стильдә) "Сагынма, җимешем, Сагынма, киләм бит". Бу җыр барышында, мин Әнвәр кырына, ягына китеп барам. Әле аны күрмим. Менә!.. Янында… бер чибәр генә, яшь кыз басып тора. Билләре, өзелә – өзелә, миннән әзгә озын буйлы, ә иң мөһиме ул зәңгәр күзле сары бөдрә чәчле кыз. Өстәүенә Лилия исемле. Аның хатыны да Лилия исемле бит. Башта әле исемен дә белмәдем. Күрдем дә кызны. Әнвәр кырына, тиз генә аңа сәлам әйтергә килдем. – Сәлам!

– Сәлам!

– Нәрсә, яңаны телисеңме?

– Ә ул авыз тутырып миңа: "Әйе".

– Ә мин сиңа бирмим!

– Нәрсәне бирмисең бу кыз белән йөрүнеме әллә?

– Әйе, барысын сөйлим синең турында!

– Ә мин сиңа бирмим. – Нәрсәне, җырларнымы?

– Әйе.

Мин: – Эм м. Уйланып тордым, икенче якка карап.

И шунда ул китте барный стойкага эчәргә инде, мин сизмәдем, тагын нәрсә эшлисең монда, җәллим шундый чакларда аны, бәгъремне. Артта Әлфия белән Дима килделәр. Мин Әнвәрне күзләр белән озатып, Әлфия белән биткә бит басып торганыбызны күреп, тизрәк Лилия янына килдем. Әлфия нишләптер гаҗәпсез хисе белән көлеп җибәрде, бахыркаем, бу күренешне күзләп смутился. (Бу Лилия хәзер Лилия Гыйматдинова җырчы булды тәки).

Мин бу арада Лилиягә әйттем, бу кеше белән бик опасно, ягъни сак бул. Аның миңа вәгъдә иткәннәрен, аның хатыны бар баласы белән. Әйттем, дә киттем. Җырлар булса, Әнвәрсез дә … килерсең, табарсың. Мин әзерәк тынычландым, киттем бәдрәф бистро янында йөрим инде шунда. Йөргән чакларда ул кызыл диваннарга утырырга булды, Лилиясе утырды инде. Юлга ул арка белән басып торган иде. Мин аны нык итеп эттем дә, сикерә – сикерә танцполга барышым. Әһә, күңелем тагын да кыза башлады.

Карыйм, икесе утыралар, араларда ышанычсызлык, арасында куркаклык күренде инде.

Әнвәр янында бер генә урын калды, мин уйладым, Ходай тели икән, утырдым янәшәгә. “Нәрсә групповуху телисеңме? Әйдә! Нәрсә комачаулый?” мәкерле дидем мин. Миңа гына карап, кызны инде онытты бугай. – Мин сине судка бирәм! – Һә, бир! – Ә мин сиңа татар заведенияләрен ябам, бер җиргә баралмассың!

–Ә смысл, мәгънәсе?

– Киттем. 3 хәтлегә чутлыйм әле. Бер ике өч. Ярар, бишкә кадәр.

Бу бит чын – чынлап безнең мәһәббәт, диеп уйладым мин шул чакта. Ә чынлыкта ул мине мескен итеп күрәсе килде.

Охрананы чакырды. Үзе басты да кыз белән гардероб ягына юнәлделәр. Ә мин аларга ияреп бастым.

– Син кая?

– Синең белән!

– Дура!

– Булса соң?

– Акылдан яза син башладыңмы әллә?!

Алдыбызга егетләр дуэты каршы очрашты. Мин берсеннән үз – үземә ышанмыйм башлаудан сорадым: "Мин акылдан язган кызга ошадыммы?"

– Ой, мин белмим. Күзләре бу егетнең як – якка йөгерделәр.

– Ә, шулайдыр, син мине белмисең, шул. Ә менә син – икенчесенә дидем мин: "Син менә беләсең, ахырысы".

Шул вакытта, ул югалып калды, елмаеп куйды да. Администратор тиз генә килде, тәнсакчылары безнең янга менделәр. Миңа әйттеләр: «Аска төшегез». Юк, бармыйм. 100 мәртәбә әйттемдер бу сүзләрне. Бер тәнсакчысы мине күтәреп алды да бер бүлмәгә алып китте, арттан тагын бер ничәсе. Бүлмәдә…. бу әле тагын бер хикәя, сөйләсәң..

Киенгәч, җылый – җылый чыктым урамга. Аның өйдәге

телефон номерын җыйдым. Трубкада хатын тавышы.

– Аллё, исәнмесез. Миңа Әнвәр кирәк иде, Ул юкмы? Ә… мин әле генә шул кичәдә булдым Әнвәр дә анда иде. Ипләп сөйләшергә тырыштым мин. Ул трубканы куйды. Ә аннан инде, ачулы тавыш белән: "Нишләп сез ирегезне карамыйсыз??" дип, әйттем.

Водитель – йөртүче тыныч кына мине алып кайтты, яшьләр күзләрнең күренмәгән якта тулалар иде.

Чыккач өем кырында әнине күрдем. Һәм күзләрдән күз яшьләре чыланып киттеләр. Китте сөйләшү, хисләрне чыгару. Ә мин бит аны һаман да сагынам. Тынычлангач, кердек өйгә, абыйга әйттек, дискотека тәнсакчылары бәйләнделәр, дип. Кердек ашханәгә, чәй эчәргә. Әни аның номерын җыя, ул ала трубканы. Әни әйтә:

– Сәлам, таныдыңмы мине?

– Әйе.

– Саргайтасың бит балаңны.

– Юк, юк, юк, юк, юк, юк, юк, юк… трубканы куйды. Әни, куркудан гаҗәпләнде. Күзләрдә яшь чыкса да, мин терелгәндәй булдым.

Каян килә шундый ирләр??! Мин аның күңелсез көзгесе кебек – мин дә бәхетсез, чөнки мин аны бик нык яратам. Ул мине һичтә уйламый, кайвакыт. Гомерем буена. Бөтен галәм бу кешедә.

Мин аңладым – мин аның белән буласым килсә, мин бик нык кеше булырга тиешмен. Ләкин хәлемнән түгел икәнне

вакытлар узгач кына, аңладым.

23. 06. 06 ел.

Йолдыз төшеүе. Мин укыган вакытта кырыс укытучымны бер ничектә гафу итәлмәдем. Тик зыяны үземә генә элəгə иде. Чөнки Ходай аны болай да гафу итмәде – ул карт кыз, кияүгә чыкмаган кыз иде, балалары да юк иде. 23 июндә мин бер хатынны очраттым- ул да аның исемле хатын булып чыкты, ул республиканың диннәр бүлегендә эшләгән хатын булып чыкты. Мин укытучыны шул вакыт гафу иттем, һәм ярты сагәть тә үтми, күземдә йолдыз төшкәнен күрдем, мин, әлбәттә, теләкләр теләдем, һәм өч ачулашкан кешене очраттым да, аларны бер – берсе белән дуслаштырдым бер – ике сүз белән.

19. 07. 06 ел.

Яратканым белән “соңгы күрешү”. Яратып китеүем дигәннән.

Соңгы күрешү яраткан кешем белән. Чөнки тормыш күзеннән ул миңа бер адым да ясамады. Аның балалары бар, һәм хатын – кызлары бар. Бу Лилия хатыны белән кагәзьдә аерылса да, алар белән торды. Мин сине яратам. Мең мәртәбә әйттемдер бу сүзләрне. Шулай итеп мин беренче мәхәббәтемне озаттым олы юлга, тормыш юлына ансыз киттем.

Таныштык, кавыштык, аерылыштык, җырдагы шикелле. Тик гәеплеме мин? Синең гәебең зурырак һәм син аны соң булсада, аңладың. Тик үзгәрмәдең.

Тик ул йөрәгемне мәңгегә әсир итте. Башка бер кешене

дә ярата алмаслык итеп тойдым үземне. Әлегә дә яратамдыр. Халкымны, үземне югалттым. Алга таба аны онытып, мин үземне башка кеше итеп күрәсем килгән иде дә, әммә ләкин нинди булырга тиешлегемне белми идем. Чөнки асылымны кузгатты. Шуңадыр үземне күңел авыруны терелттеләр. Чөнки син мине иң – иң үземне яраттың да ташладың.

Мин менә хәзер шушы сорауларга җавап эзлим. Һәм таптым.

Аңладым: аның акылы узенең ике яклы, ә йөрәге бөтенләй мең, миллион төрле якларда.

Нәкъ үзе кызларны гүргә риза салырга, тик салмый, чөнки узе дә бәхетсез.

Кайсы көнне алмасам, алар минем күз алдымда хәзер кебек күренә. Ләкин акыл белән аңлап бетермим.

Радиодан берәр җыр тыңласам, ул миннән чынлапта көлә сыман. Ничек соң күңелемне бушатыйм җырларымда. Горурлыгым җитми; бер генә булса, шатлык хисен чыгарылмам.

Шуннан бирле дингә бирелдем. Чөнки икенче егетләргә күз төшәрлек калмады. Бергә булгач икенче кеше белән аны бәхетле итәргә кирәк. Ә үзең яратмасаң янәшәдәге кешегә күңеленә яра гына саласың һәм калдырасың.

Әнвәрне сагынам шул бик.

Нишләтим соң бу хисләрне? Нишләтим соң бу безнең хисләрне?

Алар бармы, әллә соң барысы сүнде. Юк шул, бар ул. Бар.

Тик синең ышанасың килми, сөйгәнем, син куркасың.

*Наргис Харасова*

* * *

*Для изготовления обложки издания использованы фото из собственного архива и художественная работа авторов*